**КАРАР**
**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Азнакай шәһәре Советы**

Азнакай шәһәре № 165-41 «12» март 2020 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Советының 2012 елның 20 декабрендәге 86-24 номерлы карары белән расланаган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында (24.11.2014 №146-41, 25.08.2015 №174-48, 17.03.2016 №20-5, 25.08.2016 №32-8, 09.12.2016 №38-11, 29.09.2017 №56-18, 22.08.2018 №108-27, 13.12.2018 №121-29, 23.05.2019 №136-33, 22.10.2019 №149-36 карарлар редакциясендә)

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы,Татарстан Республикасының 2010 елның 23 декабрендәге 98-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» законы, 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының "Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегендә 2019 елның 30 декабрендәге ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә нигезендә

Татарстан Республикасы Азнакай шәһәр Советы карар **итте:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Советының 2012 елның 20 декабрендәге 86-24 номерлы карары белән расланаган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә (24.11.2014 №146-41, 25.08.2015 №174-48, 17.03.2016 №20-5, 25.08.2016 №32-8, 09.12.2016 №38-11, 29.09.2017 №56-18, 22.08.2018 №108-27, 13.12.2018 №121-29, 23.05.2019 №136-33, 22.10.2019 №149-36 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәршләрне кертергә:

1.1. Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасында:

- 16:44:010116:175 кадастр номерлы, 1580 кв. м мәйданлы, Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы, Азнакай шәһәре, М.Солтангалиев ур., 26 йорт адресы буенча урнашкан җир кишәрлеге өчен территориаль зонаны коммуналь объектлар зонасыннан КО Д3 җитештерү һәм эшмәкәрлек эшчәнлеген алып бару өчен кирәкле объектларга хезмәт күрсәтү зонасына үзгәртергә.

- 16:44:010116:1382 кадастр номерлы, 213 кв.метр мәйданлы, Татарстан Республикасы Азнакай шәһәре, М.Солтангалиев ур., 17Б йорт адресы буенча урнашкан җир кишәрлеге өчен территориаль зонаны КО коммуналь объектлар зонасыннан Д3 җитештерү һәм эшмәкәрлек эшчәнлеген башкару өчен кирәкле объектларга хезмәт күрсәтү зонасына үзгәртергә.

- 16:44:010116:25 кадастр номеры белән 93 кв. м мәйданлы, Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы, Азнакай ш., М.Солтангалиев ур., 1. шәһәр мунчасы районындагы 23-нче номерлы гараж янындагы җир кишәрлеге өчен территориаль зонаны КО коммуналь объектлар зонасыннан җитештерү һәм эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле объектларга хезмәт күрсәтү зонасына үзгәртергә.

- 16:44:010105:3168 кадастр номерлы, 1405 кв.метрлы булган Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы "Азнакай шәһәре" муниципаль берәмлеге өчен территориаль зонаны ЖЗ 4-6 катлы торак йортлар төзү зонасыннан П4 куркынычлылык класслы V җитештерү-коммуналь хуҗалык зонасына үзгәртергә.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatarstan.ru//.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Азнакай шәһәр Советының торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләнә.

Рәис М. З. Шәйдуллин